
Закирҗанов, Ә. Алка һәм кылыч: (Яр Чаллы театрында яңа премьера) / Ә. Закирҗанов // Мәйдан. – 2025. – №6 (283). – Б. 139-144.

# «АЛКА ҺӘМ КЫЛЫЧ»

**(Яр Чаллы театрында яңа премьера)**



Аяз Гыйләҗев исемендәге Яр Чаллы татар дәүләт драма театры үзенең тамашачысын чираттагы премьерасы – «Алтын алка» спектакле белән сөендерде. Нәфыйкъ Яһудинның «Атлы казаклар» романына нигезләнеп, Айгөл Әхмәтгалиева язган пьеса ТР Театр әһелләре берлегенең матди ярдәме белән сәхнәгә куела.

Н. Яһудин 1910 елда Оренбург өлкәсенең Яңа Чиркас авылында туа. Оренбург педагогия техникумында, Казан дәүләт педагогика институтында белем ала, мәктәпләрдә эшли. 1941 елны Җаек буенда яшәүче татар казаклары тормышына багышланган «Атлы казаклар» романын яза. Язучылар берлеге тарафыннан бастыруга тәкъдим ителсә дә, сугыш башлану сәбәпле, әсәр басылмый кала. Бары 2017 елны авторның улы язучы Марс Яһудин тырышлыгы белән «Казан утлары»нда басылып чыга. А. Әхмәтгалиева романдагы вакыйгаларны сәхнәгә яраклаштырып эшли, мәхәббәт сызыгын алга чыгара һәм социаль, милли, иҗтимагый-сәяси мәсьәләләрне шул яссылыкта ача.

Спектакльне сәхнәгә куючы режиссер – Олег Кинҗәгулов, рәссамы – Ләйсән Хөсәенова, музыкаль бизәлеше Гөлназ Закирова тарафыннан эшләнә.

XX йөз башына караган вакыйгаларда Җаек буенда яшәгән татар казаклары тормышы ачыла. Ул шуның белән кызыклы һәм гыйбрәтле. Россия киңлекләрендә таралып гомер иткән татарлар арасында казак сословиесенә караганнары да халыкның күп гасырлык традицияләрен дәвам итү омтылышы белән яши. Шуны ачу максатында спектакльгә кертелгән печән әзерләү күренеше, сабантуйларны искә алу, яшьләр никахын үткәрү кебек вакыйгалар җыр-музыка, күмәк эш яисә уен-көлке белән үрелеп, халыкның теләк-омтылышын, үзара ярдәмләшеп яшәвен алып керә һәм спектакльгә җылылык, яктылык өсти. Шул ук вакытта аларның казаклар булуы, шуңа бәйле куелган таләпләр бу сословие кешеләре тормышына билгеле бер үзгәлекләр дә алып килә. Билгеле булганча, казаклар патшага хезмәттә булып саналган һәм билгеле бер ташламалардан файдаланган. Даими

рәвештә сугыш эшенә әзерләнү, атта чабарга, кылыч белән эш итәргә өйрәнү һ.б. – барысы да ир-егетләрне ватанга тугры хезмәт итү өчен әзерләүгә юнәлтелә. Хезмәткә чакырылган очракта барлык сугыш-кирәге белән тәэмин итү өчен, ир балага 10 яшь тулганнан соң, гаилә ел саен 10 сум күләмендә казнага акча түләргә тиеш була. Хәрбиләр белән тыгыз элемтәдә булу татар казакларын рус дөньясына якынайткан, төрле уку йортларында, шул исәптән хәрби училищеларда уку мөмкинлеге биргән.



Спектакльдәге вакыйгалар ике күршенең өмә вакытындагы җылы мөнәсәбәтләрен күрсәтү белән башлана һәм яшьләр мәхәббәтенә бәйле күренешләр каршылык-интриганы үстереп җибәрә. Хисамый (ТР ның халык артисты Равил Галиев) һәм Мәгузә (ТР ның атказанган артисты Флүзә Касаева) ике ул үстереп, бүгенгесендә алар белән горурланып яшиләр. Дөрес, тормышлары җиңелдән түгел. Йорт хуҗасы зарын болай белдерә: «Чын-чынлап казачи булу өчен нәрсә кирәк? Көмеш кашлы ияре, җиз саплы камчысы, чуклы йөгәннәре белән яхшы ат, бүресен дә, куянын да тота торган озын танаулы эт, шулар өстенә тормыш итүеңнең рәте-башы булырга тиеш. Ә мин нәрсә? Мин боларның берсе белән дә мактана алмыйм». Казнага тиешле акчаны түли алмаганга, ул олы улы Миңлебайны байга ялчылыкка биргән. Күршеләре Җәләй (ТР ның атказанган артисты Рафил Сәгъдуллин) һәм Мөршидә (ТР ның атказанган артисты Алсу Хәбетдинова) исә, ике кыз үстереп, аларны күзле-башлы итү теләге белән яшиләр. Ике гаилә башлыгы да патшага тугрылык, ил каршындагы бурычларын намус белән үтәүләрен сагынып искә алалар, шул ук вакытта мөселманча көн итештән һич тә баш тартмаганнар. Әнә, Хисамый олы ул Миңлебайга Җәләй кызы Мәрьямнең колагын тешләтүен, хәзер инде кечеләре белән дә шуны эшләргә кирәклеген уен-көлке аша әйтеп уза.



Вакыйгалар үзәгендә Миңлебай (Илназ Гаффанов) белән Мәрьям (Алинә Мохлисова) арасындагы мәхәббәт һәм аның төрле сынаулар аша үтүе тора. Интриганы көчәйтү максатында авторлар сыналган алымны файдалана: Мәрьямне бай улы Гарифҗан ошатып йөри, яшьләр арасына даими керә, ә Миңлебайга исә бай кызы Сабираның күзе төшкән. Әлеге каршылык спектакльдәге хәрәкәтне үстерә барып, геройларның дөньяга карашын, чор күренешләренә мөнәсәбәтен һәм төп характер сыйфатларын ачуга да хезмәт итә.

И. Гаффанов герое горур, булдыклы, үзе һәм сөйгәне өчен тора алырдай егет булып ачыла. Ул – үзсүзле, бай улы белән каршылыкка керүдән дә курыкмый. Осталыгы белән аерылып тора. Әзерлек уеннарында ук атта йөрүе, кылычка кылыч сугышы белән танылу алган Миңлебай хәрби хезмәткә алынгач та сынатмый. Ярышларда җиңеп чыккан егетне атаман алтын кылыч белән бүләкли. «...Их, Мәрьям, байлыгым булса, сиңа менә шундый алканың алтынын бүләк итәр идем. Син бит әллә нинди алтын-көмешләргә лаек... Тик байлыгым юк шул. Сине өзелеп ярата торган кайнар йөрәгем генә бар...» – диюче Миңлебай шәхес иреген яклаучы, милли горурлыгын да саклаучы сыйфатлары белән

бирелә. Вакыйгалар барышында ул шактый тиз революцион идеяләр таратучы Петлюк йогынтысына бирелә. Социаль тигезлек, кеше хокукларын яклау өчен көрәшү фикерен әйтеп, әтисе, туганнары белән каршылыкка керә. «Намус», «вөждан», «мәхәббәт» төшенчәләрен изге дип санаган егетнең революционер Иван Петрович белән бәхәсе үзенчәлекле. Инкыйлаб барышында кешене үтерергә, мал-мөлкәтен тартып алырга туры киләчәге турында әйткәч, әлеге кеше аның каршында куркыныч бәндәгә әйләнә һәм ул... моңа кадәрге идеалларыннан баш тарта, кеше үтерергә әзер булып, кылычын күтәрә... И. Гаффановка мәхәббәт утында «яну» җитеп бетми, ул «салкын», акыл белән уйлап ярата кебек тәэсир калдыра.

Мәрьям образындагы А. Мохлисова киләчәгенә нык ышанган, сабыр, максатчан кыз булып ачыла. «Унике яшемдә үк күңелемне салып куйдым, шуннан бирле йөрәгемнән киткәне юк» дип яшәүче кыз Миңлебай белән горурлануын да яшерми. Үзе яраткан кебек, сөйгәненә дә ышана, шуңа да әлегәчә бөтен яучыларны бусагасыннан кире бора. Миңлебайга килгән авырлык-борчуларны аның белән бүлешергә әзер булып: «Сине утка ыргытсалар, утка керәм, суга салсалар – суга төшәм, гел янында булырмын, җаным», – ди ул. Шул ук вакытта Мәрьям иҗтимагый-сәяси мәсьәләләргә дә җиңел генә кереп китә һәм, үз чоры хатын-кызларын узып, позициясен, бу мәсьәләләргә җитди карашын ачык итеп әйтә: «Тик син шулай да ныгытып уйла... Нәрсә дип монавысы бәндә кебекләр безнең язмыш белән уйный соң? Нигә син ул әйткәнне генә хак юл дип санныйсың? Бәлки, ул сиңа өйдән-өйгә кереп кешеләрнең малын таларга кушар. Әйдә, мәчет манарасын кис, дияр. Аллаһ юк дип әйтергә кушар, тәүбә, тәүбә. Тыңламаган кешене кылыч белән чап, байның йортына ут төрт, дияр. Тигезлибез дип, тартып алынган малны сиңа да, миңа да бирергә кушар. Дөрес яшәми дип, ата-бабаңны каһәрләргә кушар. Тик алай итеп кем генә бәхетле була алыр? Ә бүген без бәхетле түгелмени? Җир йөзендә мәхәббәт барында, без бәхетсезмени? Әйе, мин, синең кебек, ирләрчә фикер йөртмим, гади генә, хатын-кыз булып кына уйлыйм. Дөнья тыныч булса, учагымда ут, баш өстемдә түбә булса, өйдә бишек тибрәлсә, син елмаеп кайтып кергәндә балаларым белән синең кочагыңа барып сарылсам, бәхет түгелмени... Нигә ялган ялтыравыкка алданып, алтын алкадай пар бәхетебезне җимерергә? Сиңа кирәкме ул? Кемгәдер кирәктер, ә миңа кирәкми...» Эш шуңа барып җитә ки, аның сүзләренә хәтта Атаман да: «Такая молодая, и такая мудрая!..» – дип, мөнәсәбәтен белдерә. Яшь артистканың әлеге образга алынуы ихтирамга лаек, һәм ул аны, нигездә, уңышлы башкарып чыга. Шул ук вакытта А. Мохлисовага тәҗрибә җитеп бетмәү дә сизелә. Бигрәк тә Гарифҗан белән мөнәсәбәтен ачыклаганда пафос белән сөйләшү арта, ышандыру көче кими. Әтиләре һәм сеңлесе белән станицага никахлы ирен күрергә килгәч, Гарифҗан белән очрашу мизансценасында ир хатыны түгел, бәлки ихтыярын җуйган кыз булып күренә.

Әлеге дәвер атлы казаклар тормышы Оренбург төбәге белән тыгыз бәйләнештә бирелә. Халык һәртөр бюрократлык, башбаштаклык күренешеннән азап чигә. Шуның бер чагылышы буларак, авторлар ришвәт алуны җитди мәсьәлә итеп алга куялар. Түбәнрәк чиндагы Урядник (ТРның атказанган артисты Равил Гыйләҗев) моның иерархия буенча Сотникка (Рәзил Фәхретдинов), Атаманга (ТРның халык артисты Илфат Әскәров) менүен ачыктан-ачык әйтә. Ришвәт бирү күренешен режиссер һәм рәссам төрле зурлыктагы сандыклар аша эмоциональ тәэсирле итеп ачуга ирешә. Ә инде каршылык тугач, әлеге хәрбиләрнең берсен берсе таптап китәргә әзер икәнлеге дә урын ала.

Спектакльдә үзгә урынны Муллагали бай (ТР ның халык артисты Рафик Каюмов) һәм балалары алып тора. Бай үз көче, тырышлыгы, максатчанлыгы белән әлеге дәрәҗәгә ирешкән. Ул масаючан, тәкәббер, социаль түбән катламга кимсетеп карый. Бу аның ярлы катлавыннан чыккан хатыны Хәяткә (ТР ның атказанган артисты Раушания Таһирова) мөнәсәбәтендә дә күренә. Йорттагы барлык җитди мәсьәләләрне хуҗа хәл итә. Әнә Муллагали бай мәктәп-мәдрәсә салдыруын, мәчеткә ярдәм итеп торуын искәртеп уза. Хатыны Хәят ханым бер-ике эпизодта гына күренә. Ярлы-ябагайга бүләк өләшү, әйберләр

тарату белән шөгыльләнсә дә, моның сәбәбе билгесез кала. Бай улы Гарифҗан (Руслан Әюпов) үзгә характерлы образ булып тора. Ул – усал, үзсүзле, максатчан егет. Миңлебай белән Мәрьямнең араларын бозу өчен шактый эш-гамәл кылырга өлгерә. Хөкүмәткә каршы көрәшүче Петлюкны тотуда да иң зур активлык һәм тырышлыкны ул күрсәтә. Р.Әюпов герое төрле юллар белән үз теләгенә ирешергә гадәтләнгән, ул кеше психологиясен яхшы белеп эш итә. Каршылыкның ничек хәл ителүенә мөнәсәбәте ачык бирелмәсә дә, аның Миңлебай белән дошманлыгы киләчәктә дә дәвам итәчәгенә шикләнмәскә мөмкин.

Бай кызы Сабира (Гүзәл Шамагсумова) ялчысы Миңлебайга гашыйк, әмма ул үз хисләренә хуҗа түгел. Аның егеткә тартылуы мәхәббәт хисеннән бигрәк, таза, матур, булдыклы егетне үзенеке итү теләге булып кабул ителә. Миңлебай кире каккач, Сабира аның өчен тартышудан баш тарта. Дәртле күңелен басар өчен Бәхтияр (Фирдүс Сафин) кочагына керә. Шулай да Гарифҗан һәм Сабира образлары совет чоры идеологиясеннән котыла алмыйлар. Югары сыйныф вәкиле буларак, аларның яратуы да берьяклы гына. Шуңа да никахсыз балага узган Сабираның үзен үзе үтерүе дә кызгану хисе уятмый. Аның үлеменә сәбәпче булган азгын табигатьле Бәхтиярнең чын йөзен ачучы да юк. Бары кызның абыйсы Гарифҗан гына үч алачагын әйтеп үтә. Ә менә Гатау (Эмиль Гыйбадуллин) һәм Сәрвәр (Алсу Сәгыйдуллина) образлары тамашачы күңеленә хуш килде. Бер-берсенә гашыйк булып та, аны ачыктан-ачык белдерергә кыймый йөрүләре, кирәк урында җайлап кына эти-әниләренә акыллы киңәш тә бирүләре аларны яңа яшь буын вәкилләре итеп кабул итүгә китерә.

Акмырза образындагы Эдуард Латыйповны тамашачы яратып кабул итте. Ул гаять табигый уйный, эш-гамәлләрендә авыл кешесенә хас курку, хәйләкәрлек, үз язмышына риза булып яшәү дә чагыла. Бөтен кешегә яраклаша белүченең гыйбрәтле тибы булып тора.

Спектакльгә салынган төп идеяне тамашачыга җиткерүдә Петлюк образы (Марсель Мөсәвиров) мөһим урын алып тора. Муллагали байның ялчысы кайчандыр заводта эшләгән, шунда революцион идеяләр белән танышкан. Халык арасында патшага каршы көрәш идеясен таратып йөрүче герой М. Мөсәвиров уйнавында акыллы, үз эшен белеп, аңлап башкаручы буларак ачыла. Миңлебайны һәм Бәхтиярне шактый тиз үз ягына аудара ул. Шулай да әлеге образга салынган йөкләмә бәхәскә урын калдыра. Авторлар, билгеле, совет чорында киң таралган фикерне алып керә, янәсе татар авылларына XX гасыр башында ук революцион идеяләр керә башлый, аны завод-фабрикаларда чыныгу үткән революционерлар алып килә. Татар әдәбиятында аның бер үрнәген Кави Нәҗми «Язгы җилләр» романында күрсәткән иде. Кәрим Тинчуринның «Ташкыннар» драмасында да татар крестьянының революциягә килү юлы чагылыш таба. Әлеге спектакльдә исә тәҗрибәле революционер авылга килеп, ярлы катлау арасыннан яшәп килгән тәртипләргә, хөкүмәткә каршы чыга алучыларны әзерли. Патшага каршы фетнәгә котыртуда гаепләнеп кулга алынган Петлюк һәм Миңлебай диалогы, алар бәхәсенә Мәрьямнең кушылып китүе бик тә үзенчәлекле. Бердән, XX гасыр башында большевиклар хәрәкәте башлангыч хәлендә булып, революция нәтиҗәләре әле ачык күзалланмый. Маркс, Ленин язмаларында да пролетариат диктатурасының нәрсәгә китерәсе гомуми генә бирелә. Безнең геройлар исә XX гасырда илдә булган хәлләрдән чыгып фикер йөртә, ягъни замандаш автор һәм режиссер үз фикерләрен көчләп алардан әйттерә. Икенчедән, моңа кадәр гаделлеккә, матурлыкка, ярату га ышанып яшәгән төп герой Миңлебайның кеше үтерә алуы да уйлануга урын калдыра. Дөрес, конфликтның иң югары ноктасы булган диалог-бәхәстә Петлюк башка яктан ачыла. Ул үзе яклаган идея өчен теләсә кемне үтерә, байлыгын тартып ала алуын, кирәк булса, көрәштәшләрен дә юк итәчәген әйтә. Чибәр Мәрьямне күргәч, аны үзенеке итәргә әзер булуын да яшерми. Болар барысы да моңа кадәр гаделлек яклаучы булып тоелган Петлюкның чын йөзен ачуга, аның асылда кансыз, әхлаксыз, намуссыз кеше булуын аңлауга китерә. Нәтиҗәдә Миңлебай, күңелендәге каршылыкны җиңеп, сөйгәнен яклау юлына килә һәм Петлюкка каршы кылыч күтәрә. Егетнең Мәрьям җилкәсенә шинелен салу күренеше игътибарга лаек. Моның белән режиссер сөйгәненңне, гаиләңне

яклауның ил-ватан өчен көрәшкә әзер булудан аерылгысыз икәнен тамашачыга җиткерә. Әмма әлеге өч геройның бу рәвешле үзгәреше вакыйгалар агышыннан үсеп чыкмый, эзлекле рәвештә ачылмыйча, соңгы очрашуда гына фикерләре капма-каршы якка алышына, шуңа да ышандыру көче кими. Шул рәвешле, спектакльнең финалы фикер каршылыгына, бәхәскә урын калдыра.

Һәркемгә үз аңлавыннан чыгып нәтиҗәләр ясау мөмкинлеге калдырылган спектакль тамашачы тарафыннан яратып кабул ителде. Театр коллективы тәкъдим иткән гаять гыйбрәтле тарихи вакыйгалар беркемне дә битараф калдырмый, уйлануга китерә. Спектакль патриотик рух белән сугарылган. Мәрьямгә бүләк ителгән алтын алка һәм Миңлебай осталыгы белән яулап алган алтын кылыч вакыйгаларны һәм геройларны үзара бәйләп, берләштереп торучы образ-символ булып тора. Шул рәвешле, мәхәббәткә, ватанга тугрылык кебек җитди мәсьәләләр аша заман сорауларына җавап эзләнә.

Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ,
филология фәннәре докторы,
ТРның атказанган фән эшлеклесе.
Фотолар Чаллы театры архивыннан.